ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**9 октябрь, 2021 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 32**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегендә бюджет процессы турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм бюджет процессын җайлау өлешендә Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Биектау районы прокурорының 2021 елның 24 августындагы 02-08-03-2021 номерлы «Бюджет законнарын бозуларны бетерү турында» тәкъдиме нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93 нче статьяларына таянып, Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет процессы турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Красносельский авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко

Кушымта
«Расланды»
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 октябрендәге 32 нче номерлы карары белән № 34

# «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ БЮДЖЕТ ПРОЦЕССЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья. Әлеге Нигезләмәнең хокукый җайга салу предметы

Әлеге Нигезләмә белән Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә (алга таба - муниципаль берәмлек) бюджет процессында катнашучыларның составы һәм аларның бюджет вәкаләтләре, муниципаль берәмлекнең җирле бюджеты (алга таба - җирле бюджет) проектын төзү, карау һәм раслау тәртибе, җирле бюджетны үтәү тәртибе, җирле бюджет хисабын төзү, тышкы тикшерү, карау һәм раслау тәртибе, шулай ук муниципаль финанс контроле нигезләре билгеләнә.

### 2 статья. Төшенчәләр һәм терминнар

Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы билгеләгән мәгънәдә кулланыла.

## 2 бүлек. Бюджет процессында катнашучылар һәм аларның бюджет вәкаләтләре

### 3 статья. Муниципаль берәмлектә бюджет процессында катнашучылар

Муниципаль берәмлектә бюджет процессында катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль берәмлек башлыгы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красноселҗский авыл җирлеге башлыгы (алга таба - муниципаль берәмлек башлыгы);

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы (алга таба - муниципаль берәмлек Советы);

3) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - муниципаль берәмлек Башкарма комитеты);

4) җирле бюджетны төзүне һәм үтәүне оештыруны гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башкарма комитетының вазыйфаи заты Татарстан

Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вазыйфаи заты);

5) муниципаль берәмлекнең тышкы муниципаль финанс контроле органы Биектау муниципаль районының Контроль-хисап палатасы (алга таба - контроль-хисап органы);

6) бюджет акчаларының баш бүлүчеләре (бүлүчеләре);

7) җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары (администраторлары);

8) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);

9) бюджет акчаларын алучылар.

**4 статья. Муниципаль берәмлек башлыгының бюджет вәкаләтләре**

Муниципаль берәмлек башлыгы:

1) муниципаль берәмлек Уставында билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек Советы тарафыннан финанс һәм бюджет мәсьәләләре буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларга кул куя һәм халыкка җиткерә;

2) Россия Федерациясенең бюджет законнары, муниципаль берәмлек Уставы һәм муниципаль берәмлекнең башка муниципаль хокукый актлары белән аңа беркетелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**5 статья. Муниципаль берәмлек Советының бюджет вәкаләтләре**

Муниципаль берәмлек Советы:

1) җирле бюджетны һәм аның үтәлеше турында еллык хисапны карый һәм раслый;

2) үткәрелә торган тыңлаулар барышында һәм депутат соратуларына бәйле рәвештә җирле бюджет үтәлешенең аерым мәсьәләләрен карау барышында тикшереп тора;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**6 статья. Муниципаль берәмлек Башкарма комитетының бюджет вәкаләтләре**

Муниципаль берәмлек башкарма комитеты:

1) җирле бюджет проектын төзүне тәэмин итә һәм аны кирәкле материаллар һәм документлар белән муниципаль берәмлек Советына раслауга кертә;

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы каралмаган булса, бюджетара трансфертларны бүлү методикасын һәм (яисә) бирү тәртибен эшли һәм раслый;

3) җирле бюджетның үтәлешен һәм бюджет хисаплылыгын төзүне тәэмин итә;

4) муниципаль берәмлек Советына раслауга җирле бюджет үтәлеше турында хисап тапшыра;

5) муниципаль бурыч белән идарә итүне тәэмин итә;

6) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге

Нигезләмәдә һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**7 статья. Муниципаль берәмлек Башкарма комитеты вазыйфаи затының бюджет вәкаләтләре**

Муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вазыйфаи заты:

1) җирле бюджет проектын төзи һәм аны муниципаль берәмлек Советына кертү өчен кирәкле документлар һәм материаллар белән тапшыра;

2) җирле бюджетны үтәүне оештыра;

3) бюджет хисаплылыгын төзү тәртибен билгели;

4) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Нигезләмәдә һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**8 статья. Контроль-хисап органының бюджет вәкаләтләре**

Контроль-хисап органы:

1) тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыра;

2) бюджет акчаларыннан файдалануның экономиялелеген һәм нәтиҗәлелеген билгеләүгә юнәлдерелгән эффективлылыкка аудит гамәлгә ашыра;

3) җирле бюджет турындагы карарларга, Россия Федерациясе бюджет законнарының башка муниципаль норматив хокукый актлары проектларына, шул исәптән җирле бюджет күрсәткечләренең (параметрларының һәм характеристикаларының) нигезлелегенә экспертиза үткәрә;

4) муниципаль программаларга экспертиза ясый;

5) бюджет процессына анализ һәм мониторинг ясый, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган тайпылышларны бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

6) бюджет чараларын баш урнаштыручылар, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары, җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс аудитын гамәлә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

7) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Нигезләмәдә һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**9 статья. Бюджет акчалары баш бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең) бюджет вәкаләтләре**

1. Бюджет акчаларының баш бүлүчесе:

1) расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;

2) аңа буйсынучы бүлүчеләрнең һәм бюджет акчаларын алучыларның исемлеген төзи;

3) бюджет йөкләмәләренең һәм бюджет ассигнованиеләренең үзенә расланган лимитлары чикләрендә башкарылырга тиешле чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

4) җирле бюджетның тиешле чыгымнарын планлаштыра, бюджет ассигнованиеләрен нигезләүне төзи;

5) бюджет язмасын төзи, раслый һәм алып бара, бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство карамагындагы бүлүчеләр һәм бюджет акчаларын алучылар буенча бүлә һәм җирле бюджетның тиешле өлешен башкара;

6) бюджет йөкләмәләре лимитларын булдыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

7) җыелма бюджет язмасын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

8) казна учреждениеләре булып торучы бюджет акчаларын алучыларның ведомство буйсынуындагы бюджет сметаларын раслау тәртибен билгели;

9) муниципаль биремнәрне төзи һәм раслый;

10) максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләрне һәм бюджет инвестицияләрен, аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне алучылар тарафыннан үтәүне тәэмин итә;

11) бюджет акчаларын баш бүлүченең бюджет хисабын төзи;

12) үзенә буйсынучы бюджет акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләре буенча муниципаль берәмлек исеменнән җавап бирә;

13) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Нигезләмәдә һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Бюджет чараларын бүлүче:

1) җирле бюджетның тиешле чыгымнарын планлаштыра;

2) бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы күрсәткечләр һәм (яисә) бюджет акчаларын алучылар буенча бүлә һәм җирле бюджетның тиешле өлешен башкара;

3) бюджет акчаларын баш бүлүчегә бюджет язмасын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

4) максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә;

5) бюджет акчаларының тиешле баш идарәчесе тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә бюджет акчаларының баш бүлүчесенең үз карамагында булган аерым бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

**10 статья. Җирле бюджет керемнәренең баш администраторларының (администраторларның) бюджет вәкаләтләре**

1. Җирле бюджет керемнәренең баш администраторы:

1) үзенә буйсынган җирле бюджет керемнәренең администраторлары исемлеген төзи;

2) урта сроклы финанс планын һәм (яисә) җирле бюджет проектын төзү өчен кирәкле белешмәләрне тапшыра;

3) касса планын төзү һәм алып бару өчен белешмәләр бирә;

4) җирле бюджет керемнәренең баш администраторының бюджет хисабын төзи һәм тапшыра;

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре чыганаклары исемлеге нигезендә җирле бюджет керемнәре чыганаклары реестрын алып бара;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән мондый методикага гомуми таләпләр нигезендә җирле бюджетка керемнәр керүне фаразлау методикасын раслый;

7) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Нигезләмәдә һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Җирле бюджет керемнәре администраторы:

1) җирле бюджетка түләүләрне, алар буенча пеняларны һәм штрафларны исәпләүне, исәпкә алуны һәм исәпләп чыгаруның дөреслегенә, тулысынча һәм үз вакытында башкарылуына контрольне гамәлгә ашыра;

2) җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч, пенялар һәм штрафлар түләтүне гамәлгә ашыра;

3) җирле бюджетка артык түләнгән (түләтелгән) түләүләрне, пеняларны һәм штрафларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык түләтелгән суммага исәпләнгән процентларны кире кайтару турында карар кабул итә һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кире кайтаруны гамәлгә ашыру өчен Федераль казначылык органына йөкләмә тапшыра;

4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләрне исәпләү (төгәлләштерү) турында карар кабул итә һәм Федераль казначылык органына хәбәрнамә тапшыра;

5) җирле бюджет керемнәренең баш администраторы билгеләгән очракта һәм тәртиптә җирле бюджет керемнәренең баш администраторына җирле бюджет керемнәренең тиешле баш администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне һәм бюджет хисаплылыгын төзи һәм тапшыра;

6) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акча түләү өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына тапшыра;

7) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итә;

8) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Нигезләмәдә һәм (яисә) аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**11 статья. Җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторларының (администраторларның) бюджет вәкаләтләре**

1. Җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы:

1) аңа буйсынучы администраторларның җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының исемлекләрен төзи;

2) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча кертемнәрне һәм түләүләрне планлаштыра (фаразлый);

3) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын каплау өчен билгеләнгән ассигнованиеләрнең адреслылыгын һәм аның карамагына бүлеп бирелгән акчалардан файдалануның максатчан характерын тәэмин итә;

4) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының ведомство администраторлары буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлә һәм җирле бюджетның тиешле өлешен башкара;

5) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторының бюджет хисабын төзи;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән методикага гомуми таләпләр нигезендә җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәр фаразлау методикасын раслый;

7) бюджет ассигнованиеләрен нигезләүне төзи.

2. Җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторы:

1) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча кертемнәрне һәм түләүләрне планлаштыра (фаразлый);

2) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының җирле бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында башкарылуын контрольдә тота;

3) җирле бюджетка кертемнәрне һәм җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча җирле бюджеттан түләүләрне тәэмин итә;

4) бюджет хисабын төзи һәм тапшыра;

5) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының тиешле баш администраторы тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә үз карамагында булган җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторының аерым бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

6) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Нигезләмәдә һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**12 статья. Бюджет акчаларын алучының бюджет вәкаләтләре**

Бюджет чараларын алучы:

1) бюджет сметасын төзи һәм үти;

2) бюджет йөкләмәләренең һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләренең җиткерелгән лимитлары чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм (яисә) үти;

3) үзенә каралган бюджет ассигнованиеләренең нәтиҗәлелеген, максатчан файдаланылуын тәэмин итә;

4) бюджет чараларын тиешле баш бүлүчегә (бүлүчегә) бюджет язмасын үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

5) бюджет исәбен алып бара (бюджет исәбен алып баруны тәэмин итә);

6) бюджет хисабын төзи (бюджет хисаплылыгын булдыруны тәэмин итә) һәм бюджет акчаларын алучының бюджет хисаплылыгын тиешле баш бүлүчегә (бүлүчегә) тапшыра;

7) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Нигезләмәдә һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## 3 бүлек. Җирле бюджет проектын төзү

### 13 статья. Җирле бюджет проектын төзү тәртибе һәм сроклары

1. Җирле бюджет проекты чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә төзелә.

2. Җирле бюджет проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә муниципаль берәмлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә төзелә.

3. Җирле бюджет проекты муниципаль берәмлек Советының җирле бюджет турындагы карары белән өч елга - чираттагы финанс елына һәм план чорына раслана.

4. Җирле бюджет проектын төзү - муниципаль берәмлек башкарма комитетының аерым бер өстенлеге. Җирле бюджет проектын турыдан-туры төзүне муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вазыйфаи заты башкара.

5. Җирле бюджет проектын төзү тәртибе һәм сроклары муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

### 14 статья. Җирле бюджет проектын төзү өчен кирәкле белешмәләр

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;
- Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы;
- муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;
- муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешен фаразлау;
- озак сроклы чорга муниципаль берәмлекнең бюджет фаразына (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты);
- муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына,

муниципаль программалар проектларына).

2. Җирле бюджет проектын үз вакытында һәм сыйфатлы төзү максатларында муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вазыйфаи заты муниципаль берәмлек Башкарма комитетының башка вазыйфаи затларыннан, шулай ук җирле үзидарәнең башка органнарыннан кирәкле белешмәләр алырга хокуклы.

**15 статья. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы**

1. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы ел саен өч елдан ким булмаган чорга муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә әзерләнә.

Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вәкаләтле органы (вазыйфаи заты) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Социаль-икътисадый үсеш фаразы муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан җирле бюджет проектын муниципаль берәмлек Советына кертү турында карар кабул ителү белән бер үк вакытта хуплана.

3. Җирле бюджет проектын төзү яисә карау барышында муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразын үзгәртү җирле бюджет проектының төп характеристикаларын үзгәртүгә китерә.

**16 статья. Озак сроклы бюджет планлаштыруы**

1. Озак сроклы бюджет планлаштыруы муниципаль берәмлекнең озак сроклы чорга бюджет фаразын формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Озак сроклы чорга муниципаль берәмлекнең бюджет фаразы муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә һәр өч ел саен алты елга һәм аннан да күбрәк елга әзерләнә.

Озак сроклы чорга бюджет фаразы, тиешле чорга муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразын һәм җирле бюджет турында муниципаль берәмлек Советының кабул ителгән карарын, аның гамәлдә булу чорын озайтмыйча, үзгәртергә мөмкин.

3. Муниципаль берәмлекнең озак сроклы чорга бюджет фаразын эшләү һәм раслау, гамәлдә булу чоры тәртибе, шулай ук аның составына һәм эчтәлегенә карата таләпләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәгән килеш, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

4. Озак сроклы чорга муниципаль берәмлекнең бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) муниципаль берәмлек Советының җирле бюджет турындагы карар проекты белән бер үк вакытта тапшырыла (муниципаль программаларны финанс белән тәэмин итү күрсәткечләреннән тыш).

5. Муниципаль берәмлекнең озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразын үзгәртү) муниципаль берәмлек Советының җирле бюдет турындагы карары рәсми басылып чыккан көннән алып ике айдан артмаган срокта муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан раслана (расла        налар).

**17 статья. Җирле бюджет керемнәрен фаразлау**

1. Җирле бюджет керемнәре муниципаль берәмлек Советына җирле бюджет турында карар проектын кертү көненә гамәлдә булган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразы, шулай ук күрсәтелгән датага кабул ителгән һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында үз көченә керә торган Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары һәм бюджет законнары, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм җирле бюджетның салым булмаган керемнәрен билгели торган муниципаль берәмлек Советы карарлары нигезендә фаразлана.

2. Җирле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм җирле бюджет турында карар проекты муниципаль берәмлек Советына карау өчен кертелгәннән соң кабул ителгән федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары карарлары нигезләмәләре агымдагы финанс елында җирле бюджетка агымдагы финанс елына һәм план чорына үзгәрешләр керткәндә агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.

**18 статья. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру**

Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^2$ статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгели торган методика тәртибендә һәм нигезендә гамәлгә ашырыла.

**19 статья. Салым чыгымнарының исемлеге һәм аларны бәяләү**

1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә, муниципаль программалар һәм аларның структур элементлары, шулай ук муниципаль программаларга карамый торган эшчәнлек юнәлешләре киселешендә төзелә.

2. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә ел саен гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

**20 статья. Муниципаль программалар**

1. Муниципаль программалар муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыру сроклары муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан үзе билгели торган тәртиптә билгеләнә.

3. Муниципаль программалар эшләү һәм аларны төзү, гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү тәртибе муниципаль берәмлек Башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнә.

Чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар, шулай ук элек расланган муниципаль программаларга үзгәрешләр муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән срокларда

расланырга тиеш. Муниципаль берәмлек Советы муниципаль программалар проектларын һәм аларга үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне карауны муниципаль берәмлек Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырырга хокуклы.

Муниципаль программалар җирле бюджет турындагы карарга үз көченә кергән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.

4. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме муниципаль берәмлек Башкарма комитетының программаны раслаган муниципаль норматив хокукый акты нигезендә җирле бюджет чыгымнарының һәр программага тиешле максатчан статьясы буенча җирле бюджет турындагы карар белән раслана.

5. Һәр муниципаль программа буенча ел саен аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә бәя бирелә. Күрсәтелгән бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан элек расланган муниципаль программаның чираттагы финанс елыннан башлап туктату яисә үзгәртү кирәклеге турында, шул исәптән муниципаль программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртү кирәклеге хакында карар кабул ителергә мөмкин.

**21 статья. Ведомство максатчан программалары**

Җирле бюджетта ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре күздә тотылырга мөмкин, аларны эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**22 статья. Муниципаль берәмлек Башкарма комитетының резерв фонды**

1. Җирле бюджетның чыгым өлешендә муниципаль берәмлек Башкарма комитетының резерв фондын булдыру күздә тотыла.

2. Муниципаль берәмлек Башкарма комитетының резерв фонды күләме җирле бюджет турындагы карар белән билгеләнә һәм күрсәтелгән карар белән расланган җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләменең 3 процентыннан арта алмый.

3. Муниципаль берәмлек Башкарма комитетының җирле бюджет составында каралган резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

4. Муниципаль берәмлек Башкарма комитетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында хисап җирле бюджет үтәлеше хакындагы еллык хисапка кушымта итеп бирелә.

## 4 бүлек. Җирле бюджетны карау һәм раслау

**23 статья. Җирле бюджет турындагы карарның эчтәлеге**

1. Җирле бюджет турындагы карарда җирле бюджетның җирле бюджет керемнәренең гомуми күләме, җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләме, җирле бюджет дефициты (профициты), шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, муниципаль берәмлек Советы

карарларында билгеләнгән башка күрсәткечләр (җирле бюджет турындагы карардан тыш) кергән төп характеристикаларны үз эченә алырга тиеш.

2. Җирле бюджет турындагы карар белән раслана:

1) җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге;

2) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

3) бюджет ассигнованиеләрен чыгым төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәр һәм төркемчәләр) буенча бүлү яисә чыгым төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль) программалар һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәр һәм төркемчәләр) буенча бүлү һәм (яки) чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) җирле бюджет чыгымнары классификациясенең чыгым төрләренең максатчан статьялары (муниципаль) программалар һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәр һәм төркемчәләр), шулай ук җирле бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү;

4) чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

5) гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

6) чираттагы финанс елында һәм план чорында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

7) план чорының беренче елына шартлы раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләменең 2,5 процентыннан ким булмаган күләмдә (максатчан билгеләнешкә ия Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган бюджетның чыгымнарын исәпкә алмыйча), план чорының икенче елында җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнешкә ия Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган җирле бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);

8) чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;

9) чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган агымдагы елның 1 гыйнварына, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп, муниципаль эчке бурычның югары чиге һәм (яисә) муниципаль тышкы бурычның югары чиге;

10) муниципаль берәмлек Башкарма комитетының резерв фонды күләме;

11) муниципаль берәмлек Советы билгеләгән җирле бюджетның башка күрсәткечләре.

**24 статья. Җирле бюджет турында карар проектын муниципаль берәмлек Советы каравына кертү**

1. Җирле бюджет турында карар проекты муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль берәмлек Советы каравына агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча кертелә.

2. Җирле бюджет турындагы карар проекты белән бергә муниципаль берәмлек Советына түбәндәгеләр тапшырыла:

1) муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

2) агымдагы финанс елының узган чорына муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешенә якынча йомгаклар һәм агымдагы финанс елында муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган нәтиҗәләре;

3) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы;

4) чираттагы финанс елына һәм план чорына төп характеристикалар фаразы (җирле бюджет керемнәренең гомуми күләме, җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләме, җирле бюджет дефициты (профициты);

5) җирле бюджет проектына аңлатма язуы;

6) бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәпләре;

7) чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган агымдагы елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиге һәм (яисә) муниципаль тышкы бурычның югары чиге;

8) агымдагы финанс елына җирле бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;

9) муниципаль берәмлек Советы, тышкы муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тәкъдим ителгән күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата финанс органы белән каршылыклар барлыкка килгән очракта бирелә торган;

10) җирле бюджет керемнәре чыганаклары реестрлары;

11) муниципаль программалар паспорты (күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары);

12) башка документлар һәм материаллар.

3. Җирле бюджет турында карар проекты, тапшырылган документлар һәм материаллар составы әлеге статьяның 2 өлеше таләпләренә туры килмәсә, муниципаль берәмлек Башкарма комитетына эшләп бетерүгә кайтарылырга тиеш.

**25 статья. Җирле бюджет турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар**

1. Муниципаль берәмлек Советы утырышында җирле бюджет турында карар проекты каралганчы муниципаль берәмлек Уставында һәм муниципаль берәмлек Советының тиешле карары белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән проектны гавами тыңлаулар уздырыла.

2. Гавами тыңлаулар йомгаклары буенча җирле бюджет турында карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр төзелә, алар муниципаль берәмлек Башкарма комитетына җибәрелә һәм җирле бюджет турында карар проектын карау алдыннан муниципаль берәмлек Советы игътибарына җиткерелә.

**26 статья. Җирле бюджет турындагы карар проектын карау һәм аны раслау тәртибе**

1. Җирле бюджет турында карар проектын карау әлеге Нигезләмә һәм Муниципаль берәмлек Советы регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле бюджет турындагы карар проекты муниципаль берәмлек Советына кертелгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлек Советы рәисе аны экспертиза уздыру өчен контроль-хисап органына, муниципаль берәмлек Советы депутатларына, шулай ук искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү өчен хокук иҗат инициативасының башка субъектларына җибәрә.

3. Контроль-хисап органы җирле бюджет турындагы карар проекты муниципаль берәмлек Советына кертелгән көннән алып 3 календарь көннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән проектка анализ ясый, муниципаль берәмлек Советына җирле бюджет турында карар проектын кабул итү яисә кире кагу турында бәяләмә, шулай ук булган очракта - җирле бюджет турында карар проектына төзәтмәләр әзерли һәм җибәрә.

4. Муниципаль берәмлек Советы депутатлары, хокук иҗат инициативасы субъектлары муниципаль берәмлек Советына җирле бюджет турындагы карар проекты кергән көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән проектны карыйлар һәм муниципаль берәмлек Советына кисәтүләр һәм тәкъдимнәр юллыйлар.

5. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, контроль-хисап органы бәяләмәсе, муниципаль берәмлек Советы депутатларының һәм хокук иҗат инициативасының башка субъектларының искәрмәләре һәм тәкъдимнәре муниципаль берәмлек Советы тарафыннан җирле бюджет турында карар проекты муниципаль берәмлек Советына кертелгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча карала.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлек Советы җирле бюджет турында карар проектын караргa яисә аны кире кагарга һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитетына эшләп бетерергә кайтарырга карарын кабул итә. Җирле бюджет турында карар проектын кире кагу турында карарда әлеге проектка төзәтмәләр булырга тиеш.

6. Җирле бюджет турында карар проекты муниципаль берәмлек Советы тарафыннан әлеге проект муниципаль берәмлек Советына ике укылышта кертелгән көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча карала.

7. Җирле бюджетның төп характеристикаларын карау беренче укылыш предметы булып тора:

1) җирле бюджет керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме;

2) җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләме;

3) чираттагы финанс елы ахырына муниципаль бурычның югары чиге;

4) җирле бюджет кытлыгы (профициты).

Муниципаль берәмлек Советы тарафыннан җирле бюджет турындагы карар проектын беренче укылышта караганда шулай ук аның концепциясе, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразы һәм муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре турында фикер алышалар.

8. Муниципаль берәмлек Советының беренче укылышы нәтиҗәләре буенча җирле бюджетның төп характеристикаларын раслау яисә җирле бюджет турындагы карар проектын кире кагу турында карар кабул ителә.

Җирле бюджет турындагы карар проекты беренче укылышта кире кагылган очракта, муниципаль берәмлек Советы күрсәтелгән проектны муниципаль берәмлек Башкарма комитетына эшләп бетерүгә тапшыра.

Муниципаль берәмлек Башкарма комитеты 10 календарь көн эчендә җирле бюджет турында карар проектын эшләп бетерә һәм аны беренче укылышта кабул итү өчен муниципаль берәмлек Советына җибәрә.

9. Җирле бюджет турында карар проекты буенча каршылыклар килеп чыккан очракта, муниципаль берәмлек Советы рәисе килештерү комиссиясе төзергә мөмкин, аның составы һәм эш тәртибе муниципаль берәмлек Советы тарафыннан билгеләнә.

10. Җирле бюджет турында карар проектын икенче укылышта карау предметы булып тулаем күрсәтелгән проект һәм аңа кушымталарның барысы да тора.

11. Җирле бюджет турында карар муниципаль берәмлек Советы тарафыннан агымдагы финанс елының 15 декабреннән соңга калмыйча тәмам кабул ителергә тиеш.

12. Муниципаль берәмлек Советы тарафыннан кабул ителгән җирле бюджет турындагы карар имза салу һәм халыкка җиткерү өчен муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

13. Җирле бюджет турындагы карар муниципаль берәмлек Уставында билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

14. Җирле бюджет турындагы карар 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм чираттагы финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Җирле бюджет турындагы карар агымдагы финанс елы башыннан үз көченә кермәгән очракта, җирле бюджет белән вакытлыча идарә итү Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**27 статья. Җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү тәртибе**

1. Муниципаль берәмлек Башкарма комитеты күрсәтелгән карарны хокукый җайга салу предметы булган барлык мәсьәләләр буенча җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар проектын эшләүне тәэмин итә һәм аны муниципаль берәмлек Советына тапшыра.

2. Җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар проектын турыдан-туры эшләүне муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вазыйфаи заты башкара.

3. Җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карар проектын карау һәм раслау муниципаль берәмлек Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль берәмлек Советының җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары муниципаль берәмлек Уставында билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

## 5 бүлек. Җирле бюджетны үтәү

**28 статья. Җирле бюджетны үтәү нигезләре**

1. Җирле бюджетны үтәү муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

2. Җирле бюджетны үтәүне оештыру муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вазыйфаи затына йөкләнә.

3. Җирле бюджетны үтәү җыелма бюджет язмасы һәм касса планы нигезендә оештырыла.

4. Җирле бюджет касса бердәмлеге һәм чыгымнарның ведомстволылык нигезендә башкарыла.

5. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлешенә казначылык хезмәте күрсәтү Федераль казначылык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**29 статья. Җыелма бюджет язмасы**

1. Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибе муниципаль берәмлек җирлекнең финанс органы  тарафыннан билгеләнә.

2. Җыелма бюджет язмасын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү финанс органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җыелма бюджет язмасының расланган күрсәткечләре җирле бюджет турындагы карарга туры килергә тиеш.

3. Җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән очракта, финанс органы җитәкчесе җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләрне раслый.

Җыелма бюджет язмасына Россия Федерациясе Бюджет кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган очракларда җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертмичә, финанс органы җитәкчесе карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

4. Чыгымнар буенча җыелма бюджет язмасының расланган күрсәткечләре бюджет акчаларын төп бүлүчеләргә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башына кадәр җиткерелә.

**30 статья. Касса планы**

1. Җирлекнең финанс органы  касса планын төзү һәм алып бару тәртибен, шулай ук бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары, җирле бюджет дефицитын финанслау чыганакларының төп администраторлары тарафыннан касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләрне тапшыру составын һәм срокларын билгели.

2. Касса планын төзү һәм алып бару муниципаль берәмлек Башкарма комитетының вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**31 статья. Керемнәр һәм чыгымнар буенча җирле бюджетны үтәү**

1. Керемнәр буенча җирле бюджетны үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе һәм Татарстан

Республикасы бюджет законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле бюджетны чыгымнар буенча үтәү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләрен үтәп, җирлекнең финанс органы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**32 статья. Бюджет язмасы**

1. Төп бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең) бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе, аларга үзгәрешләр кертүне дә кертеп, җирлекнең финанс органы тарафыннан билгеләнә.

Бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) чыгымнар төрләренең төркемчәләре (төркемчәләре һәм элементлары) буенча бюджет йөкләмәләренең раслана торган лимитларын детальләштерүне гамәлгә ашыру хокукын яисә бурычын билгеләргә мөмкин.

2. Бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең бюджет язмалары җыелма бюджет язмасы белән расланган бюджет ассигнованиеләре һәм финанс органы раслаган бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә төзелә.

Бюджет акчаларын бүлүчеләрнең бюджет язмалары бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләренең аларга җиткерелгән лимитлары нигезендә төзелә.

3. Бюджет язмасын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Җыелма бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә бюджет акчалары баш бүлүче чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне үзгәртү, җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә рөхсәт ителми.

Бюджет акчаларын баш бүлүченең бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә бюджет акчалары бүлүченең чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне бюджет акчалары баш бүлүченең бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә үзгәртү рөхсәт ителми.

**33 статья. Җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча җирле бюджетны үтәү**

1. Җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә җирлекнең финанс органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, җирле бюджетның бердәм счетындагы акчаларның каган өлеше белән идарә итү операцияләреннән тыш, җыелма бюджет язмасы нигезендә җирле бюджет дефицитын финанслау чыганаклары баш администраторлары, администраторлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет ассигнованиеләре исәбеннән үтәлергә тиешле акчалата йөкләмәләр өчен түләүне санкцияләү муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**34 статья. Шәхси счетлар**

1. Җирле бюджет керемнәре администраторларының операцияләрен исәпкә алу аның тарафыннан Федераль казначылыкта ачыла торган шәхси счетларда башкарыла.

2. Җирле бюджетны үтәү операцияләрен исәпкә алу финанс органында ачыла торган шәхси счетларда Федераль казначылыкта финанс органына ачыла торган шәхси счетларда, әлеге статьяда билгеләнгән очраклардан тыш, башкарыла.

3. Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле бюджетлар акчаларын алучылар вакытлы карамагына керә торган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән очракларда һәм тәртиптә кире кайтарылырга яисә күчерелергә тиешле акчалар белән операцияләрне исәпкә алу финанс органында аларга ачкан шәхси счетларда башкарыла.

4. Муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль автоном учреждениеләр акчалары белән операцияләрне исәпкә алу, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, финанс органнарында аларга ачыла торган шәхси счетларда башкарыла.

5. Бюджет процессында катнашучы булмаган юридик затлар акчалары, җирле бюджеттан бирелгән акчалар финанс белән тәэмин итү чыганагы булган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән операцияләрне исәпкә алу, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, финанс органында аларга ачыла торган шәхси счетларда башкарыла.

6. Федераль казначылыкта, Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органында, Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) финанс органында шәхси счетларны ачу һәм алып бару Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә Федераль казначылык, Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы, Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**35 статья. Бюджет сметасы**

1. Казна учреждениесенең бюджет сметасы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә казна учреждениесе буйсынган бюджет акчалары баш бүлүчесе билгеләгән тәртиптә төзелә, раслана һәм алып барыла.

Бюджет акчаларын баш бүлүченең бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы булган казна учреждениесенең бюджет сметасы әлеге орган җитәкчесе яисә әлеге орган исеменнән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эш итәргә вәкаләтле башка зат тарафыннан раслана.

2. Казна учреждениесенең бюджет сметасының расланган күрсәткечләре казна учреждениесе функцияләрен үтәүне тәэмин итү буенча бюджет йөкләмәләрен кабул итүгә һәм (яисә) үтәүгә аңа кадәр җиткерелгән лимитларга туры килергә тиеш.

Казна учреждениесенең бюджет сметасы муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар планнарын төзегәндә каралган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны сатып алуга бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә раслана торган товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуга бюджет йөкләмәләре күләмнәрен исәпкә алып төзелә.

Казна учреждениесенең бюджет сметасында казна учреждениесенең бюджет сметасын төзү һәм алып бару тәртибендә каралган башка күрсәткечләр өстәмә рәвештә расланырга тиеш.

Җитәкчесенә аны раслау хокукы бирелгән казна учреждениесенең бюджет сметасы күрсәткечләре, казна учреждениесенең бюджет сметасын раслау тәртибе нигезендә, чыгымнар төрләренең элементлары (төркемчәләр һәм элементлар) кодлары буенча бюджет йөкләмәләренең җиткерелгән лимитлары чикләрендә, шулай ук бюджет йөкләмәләренең җиткерелгән лимитлары чикләрендә дәүләт идарәсе секторының тиешле төркемнәр (статьялар) операцияләре классификациясе кодлары буенча өстәмә рәвештә детальләштерелергә мөмкин.

**36 статья. Финанслауның иң чик күләмнәре**

1. Җирлекнең финанс органы билгеләгән очракта һәм тәртиптә чыгымнар буенча җирле бюджетны үтәүне оештырганда баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә һәм бюджет акчаларын алучыларга агымдагы финанс елының тиешле чорында акчалата йөкләмәләр өчен түләүнең иң чик күләмен (финанслауның иң чик күләмнәрен) раслау һәм җиткерү күздә тотылырга мөмкин.

2. Финанслауның иң чик күләмнәре тулаем алганда баш бүлүчегә, бүлүчегә һәм бюджет акчаларын алучыларга карата баш бүлүчеләрне, бүлүчеләрне һәм бюджет акчаларын алучыларны финанслауга заявкалар нигезендә ай саен яисә квартал саен яисә агымдагы финанс елы башыннан үсә барган нәтиҗә белән билгеләнә.

**37 статья. Җирле бюджетны үтәгәндә җирле бюджет турындагы карар белән расланган керемнәрдән тыш алынган керемнәрдән файдалану**

1. Җирле бюджет турындагы карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән тыш җирле бюджетны үтәгәндә фактта алынган керемнәр Җирлекнең финанс органы тарафыннан, җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль алынмаларны биләүгә, муниципаль бурычны каплауга, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре үтәлешенә каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта, муниципаль берәмлекнең гавами норматив йөкләмәләрен үтәүгә җибәрелергә мөмкин.

2. Максатчан билгеләнешле (аларны бирү турында хәбәрнамә алган очракта) субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә җирле бюджетка керә торган, шулай ук җирле бюджет турында карар белән расланган керемнәрдән тыш, җирле бюджетны үтәгәндә фактта алынган физик һәм юридик затлардан түләүсез керемнәр, җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертмичә җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертеп, күрсәтелгән акчаларны бирүнең тиешле максатларына җирле бюджет чыгымнарын арттыруга җибәрелә.

**38 статья. Бюджетның бердәм счетында акчаларның калган өлешләре белән идарә итү операцияләре**

1. Җирле бюджетның бердәм счетындагы акчаларның калган өлешләре белән идарә итү буенча операцияләр җирле бюджетның бердәм счетында вакытлыча ирекле акчалар урнаштыру һәм җирле бюджетның бердәм счетында калган акчаларны тәэмин итү өчен акча җәлеп итүдән гыйбарәт.

2. Муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне исәпкә алып, җирле бюджет акчаларын алучыларның вакытлыча кулланылышына, казначылык счетларында, бюджет һәм Автоном учреждениеләрнең акча средстволары белән операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларында, муниципаль берәмлекнең ачык финанс органына, казначылык счетларында бюджет процессында катнашмаучы юридик затларның, бюджет һәм Автоном учреждениеләрнең, муниципаль берәмлекнең финанс органының ачык акчалары белән операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен акча калдыкларын җәлеп итә.

3. Җирлекнең финанс органы казначылык счетларына элек алардан күчерелгән җәлеп ителгән акчаларны, шул исәптән җәлеп ителгән акчалар исәбеннән операцияләр үткәрү максатларында, күрсәтелгән акчаларны алучыларның күрсәтмәләрен үтәүгә кабул ителгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, шулай ук агымдагы финанс елы тәмамланганда, әмма агымдагы финанс елының соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

4. Казначылык счетларына элек алардан күчерелгән җирле бюджетның бердәм счетыннан җәлеп ителгән акчаларны әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә кире кайтару, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне исәпкә алып, муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**39статья. Агымдагы финанс елын төгәлләү**

1. Җирле бюджетны үтәү операцияләре, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән операцияләрдән тыш, 31 декабрьдә тәмамлана.

Агымдагы финанс елында җирле бюджетны үтәү операцияләрен төгәлләү җирлекнең финанс органы тарафыннан әлеге статья таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Бюджет ассигнованиеләре, бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм агымдагы финанс елын финанслауның иң чик күләмнәре үз гамәлен 31 декабрьдә туктаталар.

3. Җирлекнең финанс органы агымдагы финанс елы тәмамланганда аларның эшчәнлеген Россия Федерациясендә эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә чираттагы финанс елының гыйнвар аенда гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар белән бюджет акчаларын алучыларны тәэмин итү тәртибен билгели.

## 6 бүлек. Бюджет хисаплылыгын төзү, тышкы тикшерү, карау һәм раслау

**40 статья. Бюджет хисаплылыгын төзү**

1. Бюджет акчаларының баш администраторлары бюджет хисаплылыгын аларга ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын алучылар (бүлүчеләр), җирле бюджет керемнәре администраторлары, җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторлары тапшырган бюджет хисаплылыгы нигезендә төзиләр.

2. Муниципаль берәмлекнең бюджет хисаплылыгы бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының бюджет хисаплылыгы нигезендә җирлек финанс органының вазыйфаи заты тарафыннан төзелә.

3. Муниципаль берәмлекнең бюджет хисаплылыгы еллык була. Җирле бюджетның үтәлеше турында хисап квартал саен исәпләнә.

4. Агымдагы елның беренче кварталында, яртыеллыгында һәм тугыз аенда җирле бюджетның үтәлеше турында хисап муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан раслана һәм муниципаль берәмлек Советына һәм контроль-хисап органына җибәрелә.

6. Җирле бюджетның үтәлеше турында еллык хисап муниципаль берәмлек Советы карары белән расланырга тиеш.

**41 статья. Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү**

1. Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисап муниципаль берәмлек Советында аны караганчы тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчалары баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерүне һәм җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

2. Җирле бюджетны үтәү турында еллык хисапны тышкы тикшерү Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, контроль-хисап органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Муниципаль берәмлек Башкарма комитеты агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, аңа бәяләмә әзерләү өчен, җирле бюджетның үтәлеше турында хисап бирә. Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер айдан артмаган срокта уздырыла.

4. Контроль-хисап органы, бюджет акчаларының баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерү белешмәләрен исәпкә алып, җирле бюджет үтәлеше турында хисапка бәяләмә әзерли.

5. Җирле бюджетның үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә муниципаль берәмлек Советына контроль-хисап органы тарафыннан муниципаль берәмлек Башкарма комитетына бер үк вакытта җибәреп тапшырыла.

**42 статья. Муниципаль берәмлек Советы тарафыннан Җирле бюджетның үтәлеше турында еллык хисапны тәкъдим итү, карау һәм раслау**

1. Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тәкъдим итү, карау һәм раслау тәртибе муниципаль берәмлек Советы тарафыннан билгеләнә.

2. Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисап муниципаль берәмлек Советына агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмыйча тапшырыла.

3. Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисап белән бер үк вакытта аңа җирле бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисаплылыгына анализны үз эченә алган аңлатма язуы һәм муниципаль биремне үтәү турындагы һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләрен файдалануның башка нәтиҗәләре турындагы белешмәләр, җирле бюджетны башкару турында карар проекты, җирле бюджет үтәлеше турында башка бюджет хисаплылыгы, Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документлар тапшырыла.

4. Җирле бюджетның үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлек Советы җирле бюджет үтәлеше турындагы карарны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

Муниципаль берәмлек Советы җирле бюджетны үтәү турындагы карарны кире каккан очракта, ул белешмәләрне дөрес яисә тулысынча чагылдырмау фактларын бетерү һәм бер айдан да артмаган срокка кабат тапшыру өчен кайтарыла.

5. Хисап финанс елында җирле бюджетның үтәлеше турында хисап җирле бюджет керемнәренең, җирле бюджет чыгымнарының һәм җирле бюджет дефицитының (профицитының) гомуми күләмен күрсәтеп, муниципаль берәмлек Советы карары белән раслана.

6. Хисап финанс елында җирле бюджетның үтәлеше турындагы карарга аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

1) җирле бюджет керемнәре классификациясе кодлары буенча җирле бюджет керемнәре;

2) җирле бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча җирле бюджет чыгымнары;

3) җирле бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча җирле бюджет чыгымнары;

4) җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;

5) муниципаль берәмлек Советы билгеләгән башка күрсәткечләр.

**43 статья. Гавами тыңлаулар**

Муниципаль берәмлек Советы утырышында хисап финанс елында җирле бюджетның үтәлеше турында хисап каралганчы, муниципаль берәмлек Советы билгеләгән тәртиптә гавами тыңлаулар уздырыла.

## 7 бүлек. Муниципаль финанс контроле

**44 статья. Муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы органнар**

1. Муниципаль финанс контрольне түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

1) контроль-хисап органы;

2) Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы вазыйфаи заты.

2. Контроль-хисап органы тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыра.

3. Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге финанс-бюджет палатасының вазыйфаи заты эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыра.

**45 статья. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча контроль-хисап органы вәкаләтләре**

1. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча контроль-хисап органы вәкаләтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, җирле бюджеттан гавами норматив йөкләмәләргә һәм физик затларга башка түләүләр буенча йөкләмәләргә шарт булган хокукый актлар нигезләмәләренең, шулай ук җирле бюджеттан акчалар бирү турында муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүгә контроль;

2) бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисаплылыгын, җирле бюджет үтәлеше турында квартал һәм еллык хисапларны төзүнең һәм тапшыруның дөреслеген, тулылыгын һәм норматив таләпләргә туры килүенә контоль;

3) «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән башка өлкәләрдә контроль.

2. Контроль-хисап органы тышкы муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда:

1) «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, билгеләнгән тәртиптә контроль һәм эксперт-аналитик чараларны аның тарафыннан гамәлгә ашыру барышында тикшерүләр, ревизияләр, анализ, тикшеренүләр, мониторинг үткәрелә;

2) контроль объектларына тәкъдимнәр, күрсәтмәләр җибәрелә;

3) мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнамә финанс органына җибәрелә;

4) административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында эшләр башкару гамәлгә ашырыла.

**46 статья. Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча финанс органы вәкаләтләре**

1. Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча финанс органы вәкаләтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган, шул исәптән муниципаль учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбенә һәм бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын төзүгә һәм тапшыруга таләпләр билгели торган хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешенә контроль;

2) җирле бюджеттан гавами норматив йөкләмәләр һәм физик затларга башка түләүләр буенча йөкләмәләр шартлары тудыручы хокукый актлар нигезләмәләрен, шулай ук җирле бюджеттан, акчалар бирү турында шартнамәләр (килешүләр), муниципаль контрактлар шартларын үтәүгә контроль;

3) җирле бюджеттан акчалар бирү турындагы шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатларында төзелгән шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда муниципаль контрактларны үтәү максатларында төзелгән шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын үтәүгә контроль;

4) бюджет акчаларын (җирле бюджеттан бирелгән акчаларны) бирү һәм (яисә) файдалану нәтиҗәләре турындагы хисапларның, шул исәптән муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турындагы хисапларның, муниципаль биремнәрне үтәү турындагы хисапларның, җирле бюджеттан акчалар бирү күрсәткечләренең билгеләренә ирешү турындагы хисапларның дөреслегенә контроль;

5) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган сатып алулар өлкәсенә контроль.

2. Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге финанс-бюджет палатасының вазыйфаи заты тарафыннан эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда:

1) тикшерүләр, ревизия һәм тикшеренүләр үткәрелә;

2) контроль объектларына актлар, бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм (яисә) күрсәтмәләр җибәрелә;

3) мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнамәләр җибәрелә;

4) административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында эшләр башкару гамәлгә ашырыла;

5) тикшерүләр, ревизияләр һәм тикшеренүләр үткәрү өчен кирәкле экспертизалар үткәрү (оештырыла) билгеләнә;

6) эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле Россия Федерациясенең мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турындагы законнары, Россия Федерациясенең закон белән саклана торган дәүләт һәм башка сер турындагы законнары нигезендә дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларына даими керү мөмкинлеге алына;

7) Россия Федерациясе Гражданнар кодексы нигезендә судка муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә яраксыз дип тану турында дәгъвалар җибәрелә.

3. Эчке муниципаль финанс контроле Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән расланган федераль стандартлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Совет рәисе,
Красносельский авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Кәлимуллин